МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**06.08.2015** Казан **№ 358**

**Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына гражданнардан һәм оешмалардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибе турында**

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 11 апрелендәге 16-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 маддәсе 3 өлешен үтәү йөзеннән һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләүгә анализ үткәрүгә бердәй якын килүне тәэмин итү максатында **боерам:**

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына гражданнардан һәм оешмалардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрүнең боерыкка беркетелгән тәртибен расларга.

2. Оештыру эшләре бүлеге башлыгы Р.Г.Зиминага елга ике мәртәбә, яртыеллыкның соңгы ае артыннан килүче айның 15 числосына кадәр, гражданнар һәм оешмалардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ (алга таба – анализ) үткәрергә.

3. Дәүләт мәгълүмат ресурслары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек бүлеге башлыгы Т.А.Апаевка анализны, яртыеллыкның соңгы ае артыннан килүче айның 15 числосыннан да соңга калмый, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

**Министр** **А.А.Здунов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгы
боерыгы белән расланган
06.08.2015 № 358

**Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына гражданнардан һәм оешмалардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 11 апрелендәге 16-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 маддәсен үтәү йөзеннән эшләнде һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына (алга таба – Министрлык) гражданнардан һәм оешмаларган кергән мөрәҗәгатьләрне (алга таба – мөрәҗәгатьләр) гомумиләштерү һәм анализ үткәрү процедурасын билгели.

2. Анализ үткәргәндә Министрлыкка кергән, башка адреска юлланган һәм каралган язма мөрәҗәгатьләр, электрон документ әйләнеше формасындагы мөрәҗәгатьләр саны турында, гражданнарны кабул итү урыны, көннәре һәм сәгатьләре турында, шәхси кабул ителгән гражданнар саны, гражданнарны шәхси кабул итәргә вәкаләтле затлар һәм күчмә шәхси кабул итүләр турында, мөрәҗәгатьләр тематикасы турында, мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар (булганда) турында мәгълүмат өйрәнелә.

3. Мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау Министрлыкның оештыру эшләре бүлеге (алга таба – Бүлек) тарафыннан электрон документ әйләнеше мәгълүматы һәм әлеге Тәртипнең 4 пунктына ярашлы тапшырылган мәгълүмат нигезендә гамәлгә ашырыла.

4. Министр, министр урынбасары - Эшкуарлыкны үстерү департаменты директоры, эшләр белән идарәчедә (алга таба – Министрлык җитәкчелеге) шәхси кабул итү вакытында кергән мөрәҗәгатьләр турында мәгълүмат Бүлеккә

Министрлык җитәкчелеге тарафыннан шәхси кабул итүгә гражданнарны язуны башкаручы белгеч тарафыннан башкарыла.

5. Әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән мәгълүмат Бүлеккә җаваплы хезмәткәрләр тарафыннан яртыеллыкның соңгы ае артыннан килүче айның 10 числосына кадәр тапшырыла.

6. Бүлек башлыгы әлеге Тәртипнең 3 һәм 4 пунктларында күрсәтелгән мәгълүматны гомумиләштерә һәм анализлый.

7. Мөрәҗәгатьләр анализы, Министрлыкның рәсми сайтында урнаштыру өчен, дәүләт мәгълүмат ресурслары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек бүлегенә юллана. Анализ, яртыеллыкның соңгы ае артыннан килүче айның 15 числосыннан да соңга калмый, Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырыла.

8. Министрлыкка гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ Министрлыкның рәсми сайтында (http://mert.tatarstan.ru/) ирекле кулланыштагы ачык мәгълүмат булып тора.